КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 апрель г.Казань № 370

2019 елда «Җиңү диктанты» дигән Бөек Ватан сугышы вакыйгалары темасына Республика тарихи диктантын үткәрү турында

Бөек Ватан сугышы тарихын өйрәнүгә киң җәмәгатьчелекне җәлеп итү, тарихи белемнәрне күтәрү һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елда «Җиңү диктанты» дигән Бөек Ватан сугышы вакыйгалары темасына Республика тарихи диктантын оештырырга һәм үткәрергә.

2. Карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

2019 елда «Җиңү диктанты» дигән Бөек Ватан сугышы вакыйгалары темасына Республика тарихи диктантын үткәрү турында нигезләмә;

2019 елда «Җиңү диктанты» дигән Бөек Ватан сугышы вакыйгалары темасына Республика тарихи диктантын үткәрү буенча Татарстан Республикасы оештыру комитеты составы;

2019 елда «Җиңү диктанты» дигән Бөек Ватан сугышы вакыйгалары темасына Республика тарихи диктантын үткәрү мәйданчыклары исемлеге.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына 2019 елда «Җиңү диктанты» дигән Бөек Ватан сугышы вакыйгалары темасына Республика тарихи диктантын уздыру мәйданчыкларын дару чаралары белән медицина персоналы, беренче медицина ярдәме чаралары белән тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына 2019 елда «Җиңү диктанты» дигән Бөек Ватан сугышы вакыйгалары темасына Республика тарихи диктантын уздыру мәйданчыкларында җәмәгать тәртибен һәм иҗтимагый иминлекне саклауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Р.Фазлыевага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин